ГЛАВА АПАСТОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 22 от 18.03.2025

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы " муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) тәртибе һәм оештыру турында Нигезләмә , «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) тәртибе һәм оештыру турында Нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 24 августындагы 175 номерлы карарына таянып

**карар бирәм :**

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2.Гавами тыңлауларны оештыручы составын-оештыру комитетын расларга:

1)Хәсәнов Айрат Мансур улы – Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;

2)Нурмиева Әминә Виктор кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;

3)Хантимиров Ленар Тәлгать улы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы урынбасары, дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты;

4)Шакирова Эльмира Фирдүс кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы;

5)Насыйбуллина Гөлнур Хәйдәр кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы ветераннарының (пенсионерларының) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иҗтимагый советы вәкиле.

3.Гавами тыңлауларны оештыручыга-оештыру комитетына гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4.Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 14 апреленнән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары Хантимиров Ленар Тәлгать улына йөкләргә.

Район башлыгы А.Г. Җиһаншин

